**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О запрете продажи несовершеннолетним бестабачной никотиносодержащей продукции, электронных систем доставки никотина и внесении изменений в отдельные законодательные акты Республики Татарстан

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
24 декабря 2019 года

Статья 1. **Предмет регулирования настоящего Закона**

Настоящий Закон в соответствии с Федеральным законом от 21 ноября 2011 года № 323-ФЗ «Об основах охраны здоровья граждан в Российской Федерации» и Федеральным законом от 24 июля 1998 года № 124-ФЗ «Об основных гарантиях прав ребенка в Российской Федерации» в целях защиты и охраны здоровья граждан устанавливает запрет продажи бестабачной никотиносодержащей продукции, электронных систем доставки никотина лицам, не достигшим восемнадцатилетнего возраста (далее – несовершеннолетние), на территории Республики Татарстан.

Статья 2. **Основные понятия, используемые в настоящем Законе**

1. Для целей настоящего Закона используются следующие основные понятия:
1) бестабачная никотиносодержащая продукция – продукция, содержащая никотин и предназначенная для потребления никотина любым способом (за исключением табачных изделий и лекарственных средств, зарегистрированных в соответствии с законодательством Российской Федерации);
2) электронная система доставки никотина – электронное устройство, используемое для преобразования жидкости для электронных систем доставки никотина в аэрозоль (пар), вдыхаемый потребителем (за исключением медицинских изделий, зарегистрированных в порядке, установленном законодательством Российской Федерации).
2. Понятия, используемые в настоящем Законе, не определенные в настоящей статье, применяются в том же значении, что и в федеральном законодательстве.

Статья 3. **Запрет продажи несовершеннолетним бестабачной никотиносодержащей продукции, электронных систем доставки никотина, а также вовлечения несовершеннолетних в потребление бестабачной никотиносодержащей продукции**

1. Запрещается продажа несовершеннолетним бестабачной никотиносодержащей продукции, электронных систем доставки никотина.

2. Запрещается вовлечение несовершеннолетних в потребление бестабачной никотиносодержащей продукции путем покупки для них либо передачи им электронных систем доставки никотина, бестабачной никотиносодержащей продукции, предложения или требования использовать электронные системы доставки никотина, употребить бестабачную никотиносодержащую продукцию любым способом.

Статья 4. **О внесении изменений в Кодекс Республики Татарстан об административных правонарушениях**

Внести в Кодекс Республики Татарстан об административных правонарушениях (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2006, № 12 (I часть); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I часть), № 9 – 10, № 12 (I часть); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I часть), № 7 (I часть), № 7 (II часть), № 10 (II часть); 2011, № 6 (I часть), № 8 (I часть), № 10 (I часть), № 11 (I часть); 2012, № 1, № 6 (I часть), № 7 (I часть), № 12 (I часть); 2013, № 1, № 2 (I часть), № 6 (II часть), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I часть), № 7, № 12 (III часть); 2015, № 3, № 4, № 12 (I часть); 2016, № 5, № 7 – 8; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 33 (часть I), № 55 (часть I), № 85 (часть I), № 94 (часть I); 2018, № 22 (часть I), № 83 (часть I) следующие изменения:

1) главу 2 дополнить статьей 2.16 следующего содержания:

«Статья 2.16. **Нарушение запрета продажи несовершеннолетним бестабачной никотиносодержащей продукции, электронных систем доставки никотина, а также вовлечение несовершеннолетних в потребление бестабачной никотиносодержащей продукции**

Нарушение запрета продажи несовершеннолетним бестабачной никотиносодержащей продукции, электронных систем доставки никотина, а также вовлечение несовершеннолетних в потребление бестабачной никотиносодержащей продукции, –

влечет наложение административного штрафа на граждан в размере от трех тысяч до пяти тысяч рублей; на должностных лиц – от тридцати тысяч до пятидесяти тысяч рублей; на юридических лиц – от ста тысяч до ста пятидесяти тысяч рублей.»;

2) в статье 7.1 цифры «2.11– 2.15» заменить цифрами «2.11 – 2.16»;

3) часть 14 статьи 8.1 после слов «статьи 2.15,» дополнить словами «статьями 2.16,».

Статья 5. **О внесении изменения в Закон Республики Татарстан «О наделении органов местного самоуправления муниципальных образований в Республике Татарстан государственными полномочиями Республики Татарстан по определению перечня должностных лиц, уполномоченных составлять протоколы об административных правонарушениях»**

Внести в статью 1 Закона Республики Татарстан от 30 июля 2010 года № 60-ЗРТ «О наделении органов местного самоуправления муниципальных образований в Республике Татарстан государственными полномочиями Республики Татарстан по определению перечня должностных лиц, уполномоченных составлять протоколы об административных правонарушениях» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2010, № 7 (II часть); 2013, № 2 (I часть), № 6 (II часть), № 7, № 10; 2014, № 7; 2015, № 3, № 4; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 55 (часть I); 2018, № 22 (часть I), № 83 (часть I); 2019, № 79 (часть I) изменение, дополнив после цифр «2.15,» цифрами «2.16,».

Статья 6. **Вступление настоящего Закона в силу**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
25 декабря 2019 года
№ 106-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Тәмәкесез никотинлы продукцияне, никотин кертү электрон системаларын балигъ булмаганнарга сатуны тыю турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 24 декабрендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнарның сәламәтлеген яклау һәм саклау максатларында Татарстан Республикасы территориясендә тәмәкесез никотинлы продукцияне, никотин кертү электрон системаларын унсигез яшькә җитмәгән затларга (алга таба – балигъ булмаганнар) сатуны тыюны билгели.

2 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр**

1. Әлеге Закон максатларында түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:
1) тәмәкесез никотинлы продукция – никотин булган һәм никотинны теләсә нинди ысул белән куллану өчен билгеләнгән продукция (Россия Федерациясе законнары нигезендә теркәлгән тәмәке әйберләреннән һәм дару чараларыннан тыш);
2) никотин кертү электрон системасы – никотин кертү электрон системалары өчен сыекчаны кулланучы сулый торган аэрозольгә (парга) әйләндерү өчен кулланыла торган электрон җайланма (Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә теркәлгән медицина әйберләреннән тыш).
2. Әлеге Законда кулланыла торган әлеге статьяда билгеләнмәгән төшенчәләр федераль законнардагы мәгънәләрендә кулланыла.

3 статья. **Тәмәкесез никотинлы продукцияне, никотин кертү электрон системаларын балигъ булмаганнарга сатуны, шулай ук аларны тәмәкесез никотинлы продукция куллануга җәлеп итүне тыю**

1. Тәмәкесез никотинлы продукцияне, никотин кертү электрон системаларын балигъ булмаганнарга сату тыела.

2. Никотин кертү электрон системаларын, тәмәкесез никотинлы продукцияне балигъ булмаганнар өчен сатып алу йә аларга тапшыру юлы, никотин кертү электрон системаларыннан файдалану, тәмәкесез никотинлы продукцияне теләсә нинди ысул белән куллану тәкъдиме яисә таләбе белән аларны тәмәкесез никотинлы продукция куллануга җәлеп итү тыела.

4 статья. **Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7, № 12 (III өлеш); 2015, № 3, № 4, № 12 (I өлеш); 2016, № 5, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 85 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2.16 статья өстәргә:

«2.16 статья. **Тәмәкесез никотинлы продукцияне, никотин кертү электрон системаларын балигъ булмаганнарга сатуны тыюны бозу, шулай ук балигъ булмаганнарны тәмәкесез никотинлы продукция куллануга җәлеп итү**

Тәмәкесез никотинлы продукцияне, никотин кертү электрон системаларын балигъ булмаганнарга сатуны тыюны бозган, шулай ук балигъ булмаганнарны тәмәкесез никотинлы продукция куллануга җәлеп иткән өчен –

гражданнарга – өч меңнән алып биш мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – утыз меңнән алып илле мең сумга кадәр; юридик затларга йөз меңнән алып йөз илле мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.»;

2) 7.1 статьяда «2.11 – 2.15» саннарын «2.11 – 2.16» саннарына алмаштырырга;

3) 8.1 статьяның 14 өлешендә «2.15 статьяның 2 өлешендә,» сүзләреннән соң «2.16,» саннарын өстәргә.

5 статья. **«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү турында**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 7 (II өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 7; 2015, № 3, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 79 (I өлеш), «2.15 статьяның 2 өлешендә,» сүзләреннән соң «2.16,» саннарын өстәп, үзгәреш кертергә.

6 статья. **Әлеге Законның үз көченә керү тәртибе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 25 декабрь
№ 106-ТРЗ